**Яр Чаллы шәһәрендә 2021 елның 1 сентябренә илкүләм проектларны тормышка ашыру турында мәгълүмат**

## 1 Демография

### 1.1. «Хатын-кызларның мәшгульлегенә ярдәм итү – өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартлары тудыру» төбәк проекты

Яр Чаллы – республиканың динамик үсешкә ия шәһәрләреннән берсе. Соңгы 5 елда гына да шәһәр халкы 9,4 мең кешегә артты. Яр Чаллыда ел саен 6 меңләп бала туа.

Шәһәрдә 129 балалар бакчасы бар, аларда 34,1 мең бала тәрбияләнә.

Бүгенге көндә 1 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларның 72,7 % ( 2019 елда – 71,4 %) мәктәпкәчә белем ала. 3 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балалар балалар бакчаларында урыннар белән 100 % тәэмин ителгән.

2021 елда «Демография» илкүләм проекты кысаларында 660 урынга исәпләнгән 3 балалар бакчасы төзү планлаштырыла, шуларның 270 урыны - 2-3 яшьлек балалар өчен:

- 34 микрорайонда «Колейдоскоп» 130 нчы балалар бакчасы төзелде. Мәктәпкәчә учреждениене «Синең йорт» компаниясе төзеде. Үтәлеш 100 %;
- 63 микрорайонда «Лучик» 131 нче балалар бакчасы төзелде. Мәктәпкәчә учреждениене «Евростиль» компаниясе төзеде. Үтәлеш 100 %;
- «Притяжение» микрорайонында «Карусель» 85 нче балалар бакчасы төзелде. Мәктәпкәчә учреждениене «СтройТраст» компаниясе төзеде. Үтәлеш 80 %.

Шулай итеп, эзлекле һәм максатчан эшләү нәтиҗәсендә 2022 елга 1,5 яшьтән алып 3 яшькә кадәрге балаларны балалар бакчаларында урыннар белән 100 % тәэмин итүгә ирешү планлаштырыла.

### 1.2. «Өлкән буын» өлкән буын гражданнарга системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм тормышка ашыру

**«Демография» илкүләм проекты кысаларында өлкән буын гражданнарга системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын күтәрү бурычы куела.** «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» ДАССУ да 22 гериатрия койкасы бар.

Шәһәрдә 12 белгеч гериатрия буенча сертификатка ия.

«Өлкән буын» өлкән буын гражданнарга системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын күтәрү программасын эшләү һәм тормышка ашыру» төбәк программасы кысаларында 7 гериатрия кабинеты булдырылды («3 нче шәһәр поликлиникасы» ДАССУ, «6 нчы шәһәр поликлиникасы» ДАССУ, «7 нче шәһәр поликлиникасы» ДАССУ, «Сугыш ветераннары өчен госпиталь» ДАССУ поликлиникасы һәм «2 нче шәһәр хастаханәсе» ДАССУ поликлиникасы, «5 нче шәһәр хастаханәсе» ДАССУ ның 5 нче, 9 нчы поликлиникалары). «Л.Н.

Ганиева исемендәге 4 нче шәһәр поликлиникасында да гериатрия кабинеты ачу өчен эш башкарыла (лицензия алу, документларны рәсмиләштерү стадиясе). Срогы – 01.12.2021 ел.

## 2. Сәламәтлек саклау

**Халыкның тормыш сыйфаты дәрәҗәсе гражданнарның сәламәтлегенә бәйле.** Гражданнарның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту безнең төп стратегик максат булып тора.

«Сәламәтлек саклау» илкүләм проектының 7 юнәлеше буенча эш алып барыла.

**«Беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтү системасын үстерү» төбәк проекты** кысаларында гражданнарны профилактик тикшерү 2021 елның 1 августына 11991 кешене тәшкил итте (еллык планның 45,7% ы).

2021 елда «Медицина ярдәме күрсәтүне оештыруның яңа моделе»н булдыру һәм аны таратуда шәһәрнең алты балалар поликлиникасы катнаша.

**«Йөрәк-кан тамырлары авыруларына каршы көрәш»** төбәк проектының бурычы – Татарстан Республикасында кан әйләнеше системасы авырулары нәтиҗәсендәге үлемнәрне киметү (2021 елда 100 мең кешегә – 505).

Ирешелгән күрсәткеч: 2021 елның 1 июленә Яр Чаллы шәһәрендә кан әйләнеше системасы авыруларыннан үлүчеләр саны 100 мең кешегә – 472.

Куркыныч янаган пациентларда йөрәк-кан тамырлары авырулары үсешен һәм йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан өзлегүләрне популяцион профилактикалау алып барыла.

**«Онкологик авыруларга каршы көрәш»** төбәк проектының максаты – Татарстан Республикасында яман шеш авыруларыннан үлемнәрне киметү (2021 елда 100 мең кешегә – 193,5)

Ирешелгән күрсәткеч: 2021 елның 1 июленә Яр Чаллы шәһәрендә онкология авыруларынан үлүчеләр саны 100 мең кешегә – 183,9.

**«Балалар сәламәтлеген саклауны үстерү, балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча инфраструктурасын булдыруны да кертеп»** төбәк проекты Татарстан Республикасында балалар үлемен киметүгә юнәлдерелгән (2021 елда 1000 балага исән тугач үлгән 4 бала туры килә).

Ирешелгән күрсәткеч: 2021 елның 1 июленә Яр Чаллы шәһәрендә кече яшьтәге балалар арасында исән туган 1000 баладан үлүчеләр саны 2,3.

Педиатриядә профилактика юнәлешен үстерү максатында (15-17 яшьтәге кызларны – акушер-гинеколог табибының профилактик медицина тикшерүләрен һәм малайларны – балалар урологы-андрологы тикшерүләрен 60,0 % ка кадәр

арттыру), 2021 елның 1 августына 15-17 яшьлек үсмер егетләрдән 3210 кеше (58,7%), кызлардан 3091 кеше (59,6%) медицина тикшерүе узган.

Шәһәрдә **«Татарстан Республикасында медицина хезмәтләре экспортын үстерү»** төбәк проекты кысаларында чит ил гражданнарының Яр Чаллы шәһәрендә күрсәтелә торган медицина хезмәтләре турында мәгълүматлы булулары дәрәҗәсен күтәрү буенча коммуникацион чаралар программалары эшләнде һәм тормышка ашырыла: ТР «Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсе» ДАССУ ның рәсми сайтында чит ил гражданнары өчен учреждениедә күрсәтелә торган медицина хезмәтләре турында мәгълүматлар бар (шул исәптән инглиз телендә дә).

Максат: 2017 ел белән чагыштырганда, медицина хезмәтләрен 2024 елгы чорга кадәр 3,3 тән дә ким булмаган күләмдә арттырырга.

2021 елда 2949 чит ил гражданына 4861,2 мең сумлык медицина хезмәте күрсәтелгән.

**Бүген табиблар белән тәэмин итү проблемасы җитди тора.**

Сәламәтлек саклау системасында кадрлар ресурсы мөһим звено булып санала.

Табиб белгечләрен җәлеп итү өчен түбәндәге программалар эшли.

2016-2020 елларда максатчан юнәлеш буенча медицина югары уку йортларында 40 студент укыды (КДМУ – 32, ИДМА – 3, Саратов ДМУ – 3, Пирогов исемендәге РНИМУ – 2).

2021 елда шундый килешүне 35 абитуриент төзеде һәм алар 2021 елның 1 сентябреннән КДМУ һәм КФУ да укый башладылар;

- муниципаль берәмлекләр өчен табибларны адреслы әзерләү социаль программасын тормышка ашыру кысаларында *(ТР Министрлар Кабинетының «ТР сәламәтлек саклау системасын кадрлар белән тәэмин итү турында» 2013 елның 18 июлендәге 503 номерлы карары)* 18 студент белем ала;

- ТР Хөкүмәте грантларын бирү программасы буенча *(ТР Министрлар Кабинетының «ТР 2014 елның 25 февралендәге 120 номерлы карары кысаларында)* хәзерге вакытта 313 табиб эшли, шуларның 16 сы 2021 елда җәлеп ителгән.

2020 елда бер ординаторга, «функциональ диагностика» белгечлеге буенча укыту һәм алга таба ТР «Ашыгыч медицина ярдәме» хастаханәсе» ДАССУ да эшкә урнаштыру өчен, шәһәр бюджетыннан 80 мең сум күләмендә компенсация түләнгән. Хәзерге вакытта 20 табибка торак арендасы өчен түләү дәвалау учреждениесе хисабына башкарыла.

*Сәламәтлек саклау системасының медицина оешмаларын квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү буенча эш дәвам итә. 2021 ел башыннан шәһәргә 103 табиб һәм 277 урта медицина персоналы җәлеп ителгән (138 табиб һәм 385 урта медицина персоналы эштән азат ителгән).*

## 3. Мәгариф

**«Мәгариф» илкүләм проекты**

«Мәгариф» илкүләм проекты – ике төп максатка ирешүгә юнәлдерелгән инициатива. Беренчесе – Россия мәгарифенең глобаль көндәшлеккә сәләтлелеген

тәэмин итү һәм Россия Федерациясенең гомуми белем бирү сыйфаты буенча дөньяның 10 әйдәп баручы илләр сафына керүе.

Икенчесе – Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә гармонияле үсешкә ия һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү.

Гомуми белем бирү учреждениеләренең матди-техник базасын тәэмин итү өчен 2021 елга компьютерлар, дәреслекләр, матур әдәбият сатып алуга 179 040,3 мең сум күләмендә субвенция бүлеп бирелде.

**«Цифрлы белем бирү мохите» ярдәмче программасы**

«Мәгариф» илкүләм проектының «Цифрлы белем бирү мохите» федераль проекты кысаларында 2021 елга Яр Чаллы шәһәренең 5 белем бирү оешмасы проектына кертелгән: № 30, 32, 42, 58, Л.Б. Васильев исемендәге Кама дәүләт автомеханика техникумы.

«Цифрлы белем бирү мохите» ФП кысаларында цифрлы технологияләрне гамәлгә кертү «Виртуаль методик кабинет» юнәлеше буенча максатчан төркемнәрне укыту аша алып барыла:

- башлангыч сыйныфлар – 21 кеше;
- математика/физика – 20 кеше;
- рус теле – 20 кеше;
- тарих/җәмгыять белеме – 20 кеше;
- чит тел – 21 кеше.

Барлыгы 102 педагог. Укулар тәмамланды.

**«Киләчәк укытучысы» ярдәмче программасы**

2021 елда педагогик һәм җитәкче хезмәткәрләрнең аерым максатчан төркемнәрен укыту оештырылачак:

- «Ата-аналар белән эшләү буенча педагог эшчәнлеге» - 24 кеше;
- «Мәктәптә тәрбия эше системасына яңа карашлар» - 24 кеше;
- «Экстремизмны һәм террорчылыкны профилактикалау буенча педагогик һәм идарә хезмәткәрләре ПК» - 17 кеше.

Шәһәр педагоглары һөнәри осталык конкурсларының төбәк этапларында катнаштылар. 2021 елда «Татарстан Республикасында Ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының региональ этабында:

- «Ел укытучысы» номинациясендә 35 нче мәктәпнең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы Александр Альменеев 2 нче урынны яулады,
- «Креатив укытучы» номинациясендә 60 нчы мәктәпнең физика укытучысы Андрей Карлин җиңүче булды;
- «Педагогик дебют» номинациясендә 3 нче урынны 35 нче мәктәпнең башлангыч сыйныф укытучысы Мария Клюева яулады.

«Иң яхшы татар теле һәм әдәбияты укытучысы» Бөтенроссия конкурсында 35 нче мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гөлнәзирә Хөсниярова лауреат булды.

«Россиянең Ел тәрбиячесе-2021» Бөтенроссия конкурсының төбәк этабында:

- «Ел тәрбиячесе» номинациясендә «Забава» 106 нчы балалар бакчасының музыка җитәкчесе Олеся Низамиева 3 нче урынны яулады;

- «Туган телдә белем һәм тәрбия бирү төркеме тәрбиячесе» номинациясендә «Подсолнушек» 82 нче балалар бакчасы тәрбиячесе Алия Муллагалиева лауреат булды.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты карары нигезендә мәгариф хезмәткәрләре арасында шәһәр һөнәри осталык конкурслары үткәрелде:

- «Яр Чаллы шәһәренең Ел укытучысы»;
- «Елның өстәмә белем бирү педагогы»;
- «Кеше тәрбияләргә»;
- «Елның педагог-психологы»;
- «Ел тәрбиячесе».

**«Һәр баланың уңышы» ярдәмче программасы**

«Һәр баланың уңышы» федераль проекты кысаларында балаларның сәләтләрен һәм талантларын үстерү һәм аларга ярдәм күрсәтү буенча чаралар тормышка ашырыла.

Өстәмә белем алучыларның саны 113 % тәшкил итә, бу – 74 173 бала. Шуларның 18 642се «белем бирү» тармагындагы өстәмә белем бирү берләшмәләренә, мәктәп түгәрәкләренә һәм берләшмәләренә 42 854 бала йөри. 12 677 бала «мәдәният» һәм «спорт» тармакларының өстәмә белем бирү учреждениеләрендә белем ала.

Әлеге ярдәмче проект кысаларында мәктәп укучылары «Проектория» Бөтенроссия ачык онлайн-дәресләрендә катнашалар:

- 2021 елның 29 мартында - «Эретеп ябыштыручы һөнәре»;
- 2021 елның 28 апрелендә - «Электромонтажчы» һөнәре;
- 2021 елның 12 маенда - «Лаборатор химик анализ» компетенциясе;
- 2021 елның 19 маенда - «Пешекче» һөнәре.

## 4. «Мәдәният»

«Мәдәният» илкүләм проектының төп максаты – 2024 елга заманча мәдәният инфраструктурасын булдыру, мәдәният оешмалары эшчәнлегенә яңа формалар һәм технологияләр кертү, Россия гражданлык тәңгәллеген ныгытуга юнәлдерелгән мәдәни инициативаларга киң ярдәм күрсәтү юлы белән мәдәниятkә җәлеп ителгән гражданнар санын арттыру.

«Мәдәният» илкүләм проектын гамәлгә ашыру максатларында Яр Чаллы шәһәре федераль проектларны тәшкил итүче 3 төбәк проектында катнаша:

1. «Мәдәният» илкүләм проекты буенча «Салих Сәйдәшев исемендәге 6 нчы балалар музыка мәктәбе» музыкаль учреждениесе 1 176,0 мең сумлык музыка уен кораллары (3 фортепиано) белән җиһазландырылды.

2. «Мәдәният» илкүләм проектының «Иҗади кешеләр» федераль проекты кысаларында мәдәният учреждениеләре тарафыннан мәдәният өлкәсендә иҗади һәм идарә итү кадрларының квалификациясен күтәрү курсларына 247 заявка җибәрелде.

3. «Цифрлы мәдәният» мәдәният өлкәсендә «Хезмәтләрне цифрлаштыру һәм мәдәният өлкәсендә мәгълүмати киңлек булдыру» төбәк проекты кысаларында 2020 елда шәһәрдә виртуаль концерт залы булдыру өчен федераль бюджеттан грант отылды. Грант «Кызыл тау» мәдәният үзәге» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе базасында 2021 елда гамәлгә ашырылачак.

## 5. «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары»

«Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проектының төп максаты – норматив таләпләргә туры килә торган автомобиль юллары өлешен арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен һәм юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә үлемнәр санын киметү.

2021 елда «Имин һәм сыйфатлы автомобиль юллары» илкүләм проекты буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенә 100 000 сум (РФ – 26 518 300 сум, ТР – 73 481 700 сум) акча каралган. Әлеге акчалар Шамил Усманов урамы буенча Халыклар дуслыгы проспектыннан Хәсән Туфан проспектына кадәр булган автомобиль юлын ремонтлау буенча эшләр башкаруга юнәлдерелә. 2021елның 10 мартында аукцион үткәрелде, аның нәтиҗәләре буенча «Автомобиль юллары предприятиесе» МУП җиңүче дип танылды.

Бүгенге көндә борт ташларын демонтажлау, асфальт-бетон катламын фрезерлау, асфальт-бетон катламының өске катламын җәю, тышкы яктырту баганалары өчен нигез салу, парковка «кесәләренә» нигез салу, борт ташларын төзекләндерү, тышкы яктырту баганаларын урнаштыру һәм асфальт-бетон катламының тигезләү катламын җәю эшләре тәмамланды. Юл билгеләре кую һәм территорияне төзекләндерү эшләре бара. Эшләрне башкару 99% тәшкил итә. Дәүләт контракты нигезендә эшләрне тәмамлау вакыты – 12.10.2021 ел.

## 6. Торак һәм шәһәр мохите

### 6.1. «Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» төбәк проекты

Шәһәрдә иҗтимагый киңлекләрне үстерүгә зур игътибар бирелә.

«Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» төбәк проекты кысаларында җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү буенча 103,9 млн. сумнан артык эш планлаштырыла:

- Гренада паркы (3 чират);
- Яшь Ленинчылар бульвары (2 чират);

Халыкның теләкләрен исәпкә алып, барлык киңлекләр буенча проектлар эшләнде, алар җәмәгать тыңлауларына чыгарылды.

### 6.2. «Торак» төбәк проекты

Хәзерге вакытта торак төзелеше күләмнәренең артуы күзәтелә. Торак мәйданнарын төп кулланучылар, кагыйдә буларак, балалы яшь гаиләләр.

Яр Чаллы шәһәре буенча 2021 елга торак тапшыру планы – 320 000 кв. м, шул исәптән:

- инвестицион торак – 250 229,5 кв. м (5096 фатирлы 32 торак йорт);

- социаль ипотека программасы буенча – 59 055,5 кв. м (594 фатирлы 3 торак йорт);

- индивидуаль торак төзелеше – 10 714,28 кв. м.

Бүгенге көндә 171,3 мең кв.м торак файдалануга тапшырылган, ягъни еллык планның 48,9% ы).

## 7. «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм шәхси инициативага ярдәм»

### 7.1. «Үзмәшгуль гражданнар эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен уңайлы шартлар тудыру» төбәк проекты

**Үзмәшгуль гражданнар өчен «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимы.**

2021 елның 2 сентябренә махсус салым режимын сайлаган теркәлгән салым түләүчеләр саны 18157 кеше тәшкил итте (план буенча 16531 кеше, үтәлеш – 110%).

- физик затлар – 17382 кеше;
- шәхси эшмәкәрләр – 775 кеше.

2021 елның узган чорында «Татарстан Республикасының Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» программалары буенча 4 үзмәшгуль кешегә 500 мең сумлык микрозаемнар бирелде.

### 7.2. «Бизнес алып баруга җиңел старт өчен шартлар һәм уңайлыклар тудыру» төбәк проекты

**Мөлкәти ярдәм күрсәтү**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен объект буенча исәпкә алу даими режимда алып барыла. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан файдалану өчен яраклы милекне ачыклаганда әлеге объектлар кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак сроклы нигездә файдалануга бирү һәм (яки) файдалануга бирү өчен муниципаль милек исемлегенә кертеләчәк.

Шәһәр Советының 2009 елның 23 маендагы 31/7 номерлы карары нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, алардан файдалану, идарә итү һәм эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертелде. Кертелгән үзгәрешләр озак вакытка исәпләнгән нигездә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль милек исемлегенә, муниципаль унитар предприятиеләргә хуҗалык алып бару хокукында һәм муниципаль учреждениеләр һәм казна предприятиеләренә оператив идарә итү хокукында беркетелгән муниципаль милекне, шулай ук җир участокларын кертергә мөмкинлек бирә.

Башкарма комитетның 2021 елның 20 маендагы 3382 номерлы карары нигезендә озак вакытка исәпләнгән нигездә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына файдалануга бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан азат булган муниципаль милек исемлеге расланды. Исемлеккә 22 объект (17 – казнадан күчемсез милек, 5 – муниципаль учреждениеләр һәм предприятиеләр балансында булган милек) *(2021 елга план күрсәткече – 25 объект)* кертелгән. Исемлек Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырылган http://nabchelny.ru/company/page/53/1283 һәм «Челнинские известия» газетасының 2021 елның 2 июнендәге 39 нчы санында басылган.

Шәһәр Советының 2009 елның 1 августындагы 32/8 номерлы карары нигезендә ташламалы шартларда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән өченче затлар хокукларыннан азат булган муниципаль милек исемлегенә кертелгән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен арендага бирү тәртибе һәм шартлары расланды.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча комиссия төзү турында» 2021 елның 3 мартындагы 1444 номерлы карары кабул ителде.

Бизнеска ярдәм итү буенча кризиска каршы чараларны гамәлгә ашыру өлешендә түбәндәге норматив-хокукый актлар кабул ителде.

1) Башкарма комитетның «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итә торган күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирү турында» 2020 елның 20 маендагы 2335 номерлы карары.

2) Башкарма комитетның «Күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 20 маендагы 2334 номерлы карары.

**3) Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итүче күчемсез мөлкәткә карата төзелгән муниципаль милекне арендалау шартнамәләре буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына**

**карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләве буенча ташламалар билгеләү турында» 2020 елның 28 маендагы 39/5 номерлы карары.**

Социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар арендага түләү буенча кичектерелгән оешмалар исемлегенә кертелүгә бәйле рәвештә, Башкарма комитет карарларына тиешле үзгәрешләр кертелде:

1. Башкарма комитетның 2020 елның 25 декабрендәге 7324 номерлы карары;
2. Башкарма комитетның 2020 елның 25 декабрендәге 7325 номерлы карары.

Аренда түләве буенча кичектереп тору мөмкинлеге бирү срогы 2021 елның 1 гыйнварына кадәр озайтылу сәбәпле, Башкарма комитет карарларына түбәндәге карарлар нигезендә тиешле үзгәрешләр кертелде:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 1 мартындагы 1352 номерлы карары;
2. Башкарма комитетның 2021 елның 1 мартындагы 1353 номерлы карары.

84 кече һәм урта эшмәкәрлек субъектына һәм оешмаларга 13,3 млн. сумлык ярдәм күрсәтелде.

**Финанс ярдәме**

2021 елның узган чорында дәүләт ярдәме суммасы 117,4 млн. сум тәшкил иткән:

- «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм итү фонды» программалары буенча 32 предприятиегә 61,7 млн сумлык микрозаемнар бирелде;
- Татарстан Республикасы Гарантия фондыннан 24 компаниягә 55,7 млн. сумлык гарантия һәм поручительлек бирелде.

**Үткәрелә торган очрашулар**

- 17.02.2021 - «Эшмәкәрлекнең актуаль проблемалары» түгәрәк өстәле
- 25.03.2021, 31.03.2021, 07.04.2021, 22.04.2021 - шәһәрнең сәнәгать өлешендә җәмәгать транспорты маршрутларын карау буенча сәнәгать мәйданчыклары җитәкчеләре белән очрашу;
- 26.03.2021 - «Гринта» ҖЧҖ ның төбәк операторы белән түгәрәк өстәл;
- 31.03.2021-Татарстан Республикасы буенча Монополиягә каршы федераль хезмәт җитәкчесе урынбасарының эшмәкәрләр белән очрашуы;
- – 21.05.2021 - «Прокурор. Хакимият. Бизнес» түгәрәк өстәле;
- 26.05.2021 - Яр Чаллы шәһәре Хакиме Н.Г.Мәһдиевның эшмәкәрлек буенча күчмә Совет форматында предприятиеләрдә булуы;
- 23.06.2021 - Татарстан Республикасы Электрон сәүдә үзәге Эксперт Советы Рәисенең шәһәрнең эшмәкәрлек җәмәгатьчелеге активы белән очрашуы;
- 24.06.2021 - Россия Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкиле Б.Ю. Титовның сәнәгать тармагы предприятиеләре, сәнәгать парклары резидентлары белән очрашуы.

**Финанс һәм юридик белем буенча укыту семинарлары**

Ел дәвамында «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге базасында палатаның финанс һәм хокук комитетлары катнашында төрле семинарлар үткәрелә:

- 12.02.2021 - «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты чараларын тормышка ашыру буенча семинар;
- 18.02.2021 - «Инвестицион нишалар» РМЦ ресурсында урнаштырылган кече бизнес субъектлары тарафыннан мәгълүматларны куллану мәсьәләсе буенча вебинар;
- 19.02.2021 - «Бизнес яшьләргә» мәгариф проекты;
- 30.03.2021 - маркетплейста интернет-кибетне эшләтеп җибәрү буенча семинар;
- 23.04.2021- «Wildberries та үз бизнесыңны ничек төзергә» вебинары;
- 25.05.2021 - «Кече һәм урта бизнес өчен практик икътисад яки банк өчен ничек кредитка сәләтле булырга» семинары;
- 24.06.2021 - «Интернет-сәүдә - эшмәкәрләрнең киләчәге» укыту-практика чарасы.

**Эшмәкәрләр өчен чаралар үткәрелде:**
- 17.02.2021-эшмәкәрләр өчен хезмәт күрсәтү ярминкәсе;
- 26.05.2021 – ИННОКАМ Кадрлар комитеты һәм сәүдә-сәнәгать палатасы каршындагы фән һәм мәгариф комитетының «Кама агломерациясенә уңай хезмәт миграциясен тәэмин итүдә территория маркетингының роле» темасына берләштерелгән уртак ачык утырышы.

### 7.3. «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары акселерациясе» төбәк проекты

**«Үстерү» программасы**

2020 елда «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары акселерациясе» илкүләм проекты кысаларында «Үстерү» программасына кергән Яр Чаллы шәһәре предприятиеләре саны 7 берәмлек тәшкил итте. Программага керү нәтиҗәләре буенча әлеге предприятиеләр өчен индивидуаль үсеш карталары эшләнгән һәм расланган. Тагын 16 предприятие белән 2019 елдан ИКР чараларын үтәү программасы кысаларында эш алып барыла.

2021 елда РКК (төбәк квалификация комиссиясе) утырышы нәтиҗәләре буенча программага Яр Чаллының 5 компаниясе сайлап алынды. Әлеге предприятиеләр өчен ИКР (үсешнең шәхси карталары) эшләнгән һәм эш программа кысаларында алып барыла.

**Бизнес-миссияләр, ярминкәләр үткәрү**

Җитештерү һәм сәүдә кооперациясе максатында 2021 ел башыннан бирле «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге каршында тәэминатчыларны сайлап алу үзәге тарафыннан бизнес-миссия оештырылды:
- 02-04. 03.2021 - Омск шәһәре;

Татарстан Республикасы Машина төзелеше кластеры тарафыннан Яр Чаллы эшмәкәрләре катнашында Мәскәү шәһәрендә бизнес-миссия оештырылды.

Яр Чаллыда Чиләбе, Түбән Новгород, Түбән Новгород, Венгрия дәүләтләреннән делегацияләр булды.

Җитештерүчеләр һәм продукцияне кулланучылар арасында тиешле хезмәттәшлекне булдыру өчен шәһәр ярминкәләре үткәрелә. 2021 елның узган чорында төрле юнәлештәге 29 ярминкә уздырылды, шул исәптән 9 авыл хуҗалыгы ярминкәсе. Авыл хуҗалыгы ярминкәләренә 55 млн.нан артык сумга 400 тоннадан артык авыл хуҗалыгы продукциясе китерелде.

Ярминкәләрдә җирле азык-төлек эшкәртү сәнәгате предприятиеләре, Татпотребсоюз предприятиеләре, шулай ук крестьян-фермер хуҗалыклары, шәхси ярдәмче хуҗалык хуҗалары, шәхси эшмәкәрләр катнаша.

Моннан тыш, шәһәр территориясендә «ЭКСПО-КАМА» күргәзмә үзәге белән берлектә «Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре Сәүдә-сәнәгать палатасы» берлеге тарафыннан ярминкәләр уздырылды.

1. **Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм**

**Хезмәт җитештерүчәнлеге – икътисадны үстерүнең иң төп шартларыннан берсе.**

Яр Чаллы шәһәрендә «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм» илкүләм проектында бүгенге көндә 32 оешма катнаша, шул исәптән:

- **төбәк компетенцияләр үзәге аша - 18 оешма** («ТЭМПО «Кама металл конструкцияләре заводы» ЯАҖ, «ПТФК «ЗТЭО» ЯАҖ, «Кама» АПК ҖЧҖ, «ТАТПРОФ» АҖ, «Ар Си Эр» ҖЧҖ, «РИАТ» ААҖ, «Трансмаш» Кама заводы ПКФ ҖЧҖ, «Кориб «Авторемонт заводы» ҖЧҖ, «Тукай племрепродукторы» ҖЧҖ, «Яр Чаллы инкубаторы» ҖЧҖ, «Автомобиль юллары предприятиесе» МУП, «ТЭМПО – ЛОГИСТИК» ҖЧҖ, «Агросила - сөт» ҖЧҖ, «Агросила-Сервис» АҖ, «ЧАЛЛЫ ИКМӘГЕ» АҖ, «Техно - Логика» ҖЧҖ, «СОФТ Пайп» ҖЧҖ, «РБР 16» ҖЧҖ);
- **федераль компетенцияләр үзәге аша - 9 оешма** («Автомастер» ҖЧҖ, ПТФК «Технотрон» ҖЧҖ, «Ак Барс Металл» ҖЧҖ, «Ремдизель» АҖ, «Хайер Фридж РУС» ҖЧҖ, «САТУРН» ҖЧҖ, ПО Промвест» ҖЧҖ, НПФ «РОСТАР» ҖЧҖ, НПП «РУ-Инжиниринг» ҖЧҖ);
- **тышкы консультантлар ярдәме белән проектны мөстәкыйль тормышка ашыру өчен - 5 оешма** («ТЕХНОТРОН-МЕТИЗ» ҖЧҖ, КМК «ТЭМПО» ҖЧҖ, «Электротранспорт» ҖЧҖ, «Бетон заводы» ҖЧҖ, «ПК Акульчев» ҖЧҖ).

Татарстан Республикасында проектта катнашучыларның төп өлешен Яр Чаллы шәһәре предприятиеләре тәшкил итә. Аларның өлеше - **26,0%.** Шәһәрдә проект критерийларына туры килә торган тагын 89 предприятие катнаша ала. Илкүләм проектның ярдәм күрсәтү чаралары турында аларга мәгълүмат җиткерү буенча актив эш алып барыла.

2021 елның февралендә Кама сәнәгать форумы кысаларында «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты чараларын гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча семинар узды.

2021 елның 19 маенда шәһәрнең сәүдә-сәнәгать палатасында проектның потенциаль катнашучылары Татарстан Республикасының компетенцияләр үзәге вәкиле белән очраштылар.

«Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм» илкүләм проекты кысаларында 2020 елда уку өчен шәһәрнең Эш белән тәэмин итү үзәге аша 6,7 млн сум акча бүлеп бирелгән. Субсидияләр НПО «РОСТАР» ҖЧҖ, «Ар Си Эр» ҖЧҖ, «Технотрон-Метиз» ҖЧҖ, «ПТФК ЗТЭО» ЯАҖ хезмәткәрләрен укытуны оештыруга юнәлдерелгән.

Укыту «Персоналны мотивацияләү системасы: инструментлар, технологияләр, заманча алымнар», «Корпоратив укыту системасын камилләштерү һәм персоналны заманча шартларда үстерү», «Персонал буенча менеджерның һөнәри эшчәнлеге», «Нәтиҗәле җитәкче формалаштыру», «Халык алдында чыгыш ясау осталыгы», «Кеше ресурслары белән идарә итүдә цифрлы технологияләр», «Халыкара стандартлар нигезендә проектлар белән идарә итү» программалары буенча оештырылды. Укуларны **483** кеше үтте.

2021 елда «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү» илкүләм проектына «Техно-Логика» ҖЧҖ, «Софт Пайп» ҖЧҖ һәм «КИТ Строй» ҖЧҖ керә. «РБР 16» ҖЧҖ ның тагын 1 предприятиесе кул кую стадиясендә.

Илкүләм проектта катнашучылар саны турында динамикадагы мәгълүмат, еллар буенча

| Ел | 2019 | 2020 | 2021 |
|---|---|---|---|
| Катнашучылар саны | 26 | 29 | 32 |

Башкарма комитетның матбугат хезмәтенә «Хезмәт җитештерүчәнлеге» илкүләм проекты буенча 2 инфоповод җибәрелде, шулай ук 2 инфоповод шәһәр һәм РРК (контент җыю һәм бүлү) сайтларында урнаштырылган.

## 2. Халыкара кооперация һәм экспорт

Сәнәгать предприятиеләренә конкурентлык сәләтен арттыруның корпоратив программасын гамәлгә ашыруга субсидия алу өчен сайлап алуда катнашу мөмкинлеге турында мәгълүмат шәһәрнең 500 оешмасына электрон адреслар буенча җибәрелде.

2021 елның 24-26 февралендә «Экспо-Кама» күргәзмәләр үзәгендә Кама сәнәгать форумы уздырылды, анда якын чит ил компанияләре катнашты. Әлеге чараны уздыру һәм күргәзмә чараларында катнашу мөмкинлеге турында 500 кече һәм урта эшмәкәрлек предприятиеләре субъектларына хәбәр ителде.

2021 елның 22 апрелендә «Татарстан Республикасы Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» Коммерцияле булмаган микрокредит компаниясенең Экспортка

ярдәм үзәгенең (алга таба – ЭЯҮ) һәм шәһәрнең кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән очрашты.

Бизнес вәкилләре үз эшчәнлекләре барышында очрый торган проблемалар турында сөйләделәр, шулай ук үзләрен кызыксындырган сорауларын бирделәр.

2021 елның 17 июнендә «Автомобиль автокомпонентларын заманча җитештерүдә автоматлаштыру һәм роботлаштыру» темасына конференция үткәрелде. Конференция кысаларында сәнәгать предприятиеләрен роботлаштыру, автоматлаштыру һәм роботлаштыру буенча актуаль темалар, әзер карарлар, гамәлдәге һәм планлаштырылган ярдәм программалары карап тикшерелде, шулай ук әлеге өлкәдә дөнья лидерлары вәкилләре белән B2B очрашулары булды.

Экспорт потенциалын ачыклау максатында даими рәвештә эшмәкәрләргә ЭЯҮ хезмәтләрен алу мөмкинлеге турында мәгълүмат җиткерелә. 2021 елда экспорт скорингын шәһәрнең 10 предприятиесе узды.

## 3. **Экология**

**«Яр Чаллы шәһәре территориясендә Мәләкәс елгасы түбән, Мәләкәс култыгын чистарту»**

«Уникаль су объектларын саклау» Федераль проекты составына кертү өчен «Экология» илкүләм проекты кысаларында Татарстан Республикасы тарафыннан «Яр Чаллы шәһәре территориясендә Мәләкәс елгасы түбән, Мәләкәс култыгын чистарту» чарасы тәкъдим ителде.

Җир участогы: «Жемчужина» шифаханәсе районындагы плотинадан елга тамагына кадәрге елга үзәне.

Максатчан билгеләнеш:

- гидрологик режимны яхшырту;
- санитар-техник торышны яхшырту.

Проект эшләренең якынча бәясе: 9 954 230 сум

Эшләрнең якынча бәясе 250 млн. сум тәшкил итә.

Яр Чаллы шәһәре территориясендә Мәләкәс елгасы түбән, Мәләкәс култыгын чистарту буенча проект эшләрен башкару Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының үзара хезмәттәшлеге турындагы килешү кысаларында, 2021 елга планлаштырылган табигатьне саклау чаралары исемлегенә кертелгән. Проект эшләренең бәясе 10 661,99 мең сум тәшкил итә.

Хәзерге вакытта «Яр Чаллы шәһәре янында Мәләкәс елгасы агымын чистарту» объекты буенча проект эшләрен башкаруга смета исәп-хисаплары, техник йөкләмә Яр Чаллы шәһәре Казначылык Департаментының территориаль бүлегендә килештерү уза.

**«Яр Чаллы шәһәрендә яңгыр канализациясе челтәрләренең локаль чистарту корылмаларын төзү»**

«Иделне савыктыру» Федераль проекты составына кертү өчен «Экология» илкүләм проекты кысаларында Яр Чаллы шәһәрендә яңгыр сулары

канализациясенең локаль чистарту корылмаларын төзү буенча чаралар тәкъдим ителде.

Проект эшләренең якынча бәясе: 115 млн. сум.

Эшләрнең якынча бәясе 2,5 млрд. сум тәшкил итә.

2019 елда Башкарма комитет тарафыннан бу юнәлештә түбәндәге эшләр башкарылды:

«ПЦ Град» - чистарту корылмаларын һәм яңгыр сулары канализациясе челтәрләрен проектлауга киткән чыгымнарның бәясе билгеләнде;

- 08.05.2009 - яңгыр сулары канализациясе челтәрләренең локаль чистарту корылмаларын урнаштыру өчен җир участокларына комиссия тикшерүе үткәрелде. Җир участокларын тикшерү акты Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына җибәрелде;

- 2019 елда техник йөкләмә проектының 1.2 пунктында күрсәтелгән локаль чистарту корылмаларын урнаштыру өчен 8 җир участогы кадастр исәбенә куелды. Соңгы җир участогын кадастр исәбенә кую эше дәвам итә. Әлеге эшләр тәмамланганнан соң, җир участокларына хокук билгели торган документлар Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына тапшырылачак;

- Яр Чаллы шәһәрендә яңгыр сулары канализациясе челтәрләренең локаль чистарту корылмаларын төзү өчен проект-смета документларын эшләү буенча смета исәп-хисаплары һәм техник йөкләмә проекты әзерләнде. Хәзерге вакытта әлеге документлар пакеты Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында карала;

- «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя кую идарәсе» ДАУ тарафыннан 2020 елның 5 ноябрендә Яр Чаллы шәһәренең яңгыр сулары канализациясе челтәрләренең локаль чистарту корылмаларын төзү буенча проект-тикшеренү эшләрен башкаруга смета исәп-хисапларын тикшерү нәтиҗәләре буенча бәяләмә алынды. Тикшерү нәтиҗәләре буенча проект-тикшеренү эшләрен башкаруга чыгымнар бәясе НДС белән - 2020 елның IV кварталына 115 395 870 сум тәшкил итә;

- 2020 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары В. Н. Кудряшев адресына Башкарма комитет тарафыннан Яр Чаллы шәһәренең яңгыр сулары канализациясе челтәрләренең локаль чистарту корылмаларын төзү буенча проект-тикшеренү эшләрен финанслауга 115 395,87 мең сум күләмендә ярдәм зарурлыгы турында хат җибәрелде;

- 2020 елның декабрендә «Яр Чаллы шәһәре яңгыр сулары канализациясе челтәрләренең локаль чистарту корылмаларын төзү буенча техник йөкләмә проектын карау турында» хат алынды;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары В. Н.Кудряшев адресына Башкарма комитет тарафыннан «Яр Чаллы» спорт комплексы районында Габдулла Тукай исемендәге яр буеның яңгыр сулары канализациясе челтәренең локаль чистарту корылмаларын төзү» объекты буенча, кергән кисәтүләрне исәпкә алып, техник йөкләмә проекты җибәрелде.

Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министры А.В. Шадриков, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов һәм министрлыкның Кама буе территориаль идарәсе башлыгы Н. Г. Гарипов тарафыннан 2021 елда Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты хисабыннан табигатьне саклау чараларын үтәүне тәэмин итү буенча Татарстан Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының үзара эшчәнлеге турында килешү имзаладылар. Хәзерге вакытта «СГР» МУП тарафыннан түбәндәге адреслар буенча урнашкан ике локаль чистарту корылмасы өчен эшләр башкаруга проектлар эшләнә:

1) Г.Тукай исемендәге яр буе. (5 микрорайон каршында).
2) Г.Тукай исемендәге яр буе һәм М. Җәлил проспекты чаты.

Башкарма комитет
Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотова